**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2016 ел, 6 декабрь

№ 901

г. Казань

Техник паспортлар, дәүләт техник исәпкә алу һәм техник инвентарьлаштыру объектлары турындагы бәяләү документлары һәм башка исәпкә алу-техник документлар күчермәләрен һәм аларда булган мәгълүматларны бирү тәртибен һәм Техник паспортлар, дәүләт техник исәпкә алу һәм техник инвентарьлаштыру объектлары хакындагы бәяләү документлары һәм башка исәпкә алу-техник документлар күчермәләрен һәм аларда булган мәгълүматларны биргән өчен түләү алу һәм кайтару, түләү күләмнәрен билгеләү тәртибен раслау турында

«Күчемсез мөлкәт дәүләт кадастры турында» 2007 ел, 24 июль, ФЗ-221 нче Федераль законның 45 статьясындагы $2^7$ өлешен тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Техник паспортлар, дәүләт техник исәпкә алу һәм техник инвентарьлаштыру объектлары турындагы бәяләү документлары һәм башка исәпкә алу-техник документлар күчермәләрен һәм аларда булган мәгълүматларны бирү тәртибен;

Техник паспортлар, дәүләт техник исәпкә алу һәм техник инвентарьлаштыру объектлары турындагы бәяләү документлары һәм башка исәпкә алу-техник документлар күчермәләрен һәм аларда булган мәгълүматларны биргән өчен түләү алу һәм кайтару, түләү күләмнәрен билгеләү тәртибен.

2. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Техник инвентарьлаштыру бюросы» республика дәүләт

унитар предприятиесенә әлеге карарның тиешенчә үтәлүен тәэмин итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\901.doc